Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2018 ел, 24 сентябрь

№ 21

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әлмәт авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Әлмәт авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Референдум уздыруны инициацияләү турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 19 номерлы карары нигезендә, Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Әлмәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

**" I төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән кешеләрдән, уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан тыш, 2019 елда Әлмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме:**

1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су һәм ягулык тәэмин итү, шул исәптән:
- Әлмәт авылының 3 нче номерлы артезиан скважинасына төзелеш материаллары һәм коймалар сатып алу;

2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тотуны тормышка ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шул исәптән:
- Әлмәт авылында урам утларын карап тоту (яктырткычларны монтажлау һәм демонтажлау, таймер сатып алу һәм урнаштыру);
- Әлмәт авылында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар санкцияләнмәгән урыннарны чистарту;
- Әлмәт авылында аншлагларны, кече архитектура формаларын, чишмәне яңарту өчен буяулар сатып алу;

- триммерларны ремонтлау өчен запас частьләр;
- Әлмәт авылында югары буйлы агачларны кисү;
- "Сабантуй» мәйданын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм эскәмияләр урнаштыру);

3. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына, шул исәптән юл эшчәнлеге:
- Әлмәт авылында вак таш ташу;

4. Җирлек халкын ял иттерүне оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән:
- Әлмәт авылында Сабантуй милли бәйрәмен, 9 май, өлкәннәр, инвалидлар көненәрен үткәрү өчен призлар һәм бүләкләр;
- район "Сарман" газетасында котлаулар һәм некрологларны бастырып чыгару;

5. Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрү, шул исәптән:
- Әлмәт авылында үткәрелә торган спорт чаралары (теннис һәм волейбол ярышлары) өчен призлар сатып алу?

ӘЙЕ ЮК

3. Мәгълүмат стендларында һәм Әлмәт авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә әлеге карарны игълан итәргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Әлмәт авыл җирлеге
Советы рәисе Д.Ә.Газизов